ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**14.09.2023**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 2795**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 13 августындагы 1919 номерлы карары белән расланган, төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында (2022 елның 4 маендагы 1072 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацының үз көчен югалтуын тану хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 13 августындагы 1919 номерлы карары (2022 елның 4 маендагы 1072 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр ) белән расланган, төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба - административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Административ регламентның 1.5 пунктындагы 3 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3) җир кишәрлегендә ярдәмче файдаланудагы корылтылар һәм корылмалар төзү, аларга кертү критерийлары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә»».

2. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru ) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы З.Ф. Хәбибуллин